| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

ПРИКАЗ № 167/о БОЕРЫК

"09" 10 2018

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 20 апрелендәге 79/о номерлы, 2017 елның 05 сентябрендәге 155/о номерлы, 2017 елның 25 декабрендәге 226/о номерлы, 2018 елның 11 апрелендәге 63/о номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымтада бирелгән үзгәрешләрне кертергә.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның «09» 10 № 167/о боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 октябрендәге 167/о номерлы боерыгы белән расланган Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.3.2 пунктчада:

бишенче абзацта «(http://uslugi.tatar.ru)» сүзләрен «(https://uslugi.tatarstan.ru)» сүзләренә алмаштырырга,

тугызынчы абзацта «белешмәләрне үз эченә ала» сүзләреннән алда «Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – ШрК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) һәм дәүләт хакимияте башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 42, 5005 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 40, 3822 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт белән идарә итү системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты указы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы: (http://www.pravo.gov.ru), 2012, 7 май, бастырып чыгару номеры: 0001201205070016);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәтен оештыру һәм күрсәтү тәртибе турында» 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карары белән расланган Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын оештыру һәм уздыру турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2007, № 11, 1336 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Проект документациясенең бүлекләре составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында» 2008 елның 16 февралендәге 87 номерлы карары белән расланган Проект документациясенең бүлекләре составы һәм аларның эчтәлегенә карата таләпләр турында нигезләмә (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2008, № 8, 744 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Капиталь төзелеш объектларының проект документациясенә экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрын формалаштыру тәртибе һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 5 мартындагы 145 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 24 июлендәге 878 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 32, 5068 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр һәм дәүләт биреме (заказы) яисә муниципаль бирем (заказ) урнаштырыла торган башка оешмалар тарафыннан күрсәтелүче, электрон формада күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр реестрларына кертелергә тиешле хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2011 елның 25 апрелендәге 729-р номерлы 729-р номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыгы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 18, 2679 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәлүен тикшереп тору өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары структурасын Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы буенча федераль агентлык белән килештерү тәртибе турында» 2007 елның 3 маендагы 36 номерлы боерыгы белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәлүен тикшереп тору

өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары структурасын Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы буенча федераль агентлык белән килештерү тәртибе турында нигезләмә (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, № 46, 2007);

Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы буенча федераль агентлыкның «Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә бирелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәләре реестрын алып бару һәм әлеге Реестрда булган белешмәләрне бирү тәртибе турында» 2007 елның 2 июлендәге 186 номерлы боерыгы белән расланган Проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә бирелгән дәүләт экспертизасы бәяләмәләре реестрын алып бару һәм әлеге Реестрда булган белешмәләрне бирү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Реестр алып бару тәртибе турында нигезләмә) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, № 31, 2007, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының «Проект документациясенә дәүләт экспертизасы, инженерлык эзләнүләренә дәүләт экспертизасы оештыру һәм уздыру өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисаплылык эчтәлеген һәм формасын раслау турында» 2011 елның 20 декабрендәге 584 номерлы боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, № 14, 2012);

Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының «Проект документациясенә экспертиза һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәләренә шикаять белдерү тәртибен раслау турында» 2012 елның 23 мартындагы 126 номерлы боерыгы (Российская газета, 2012, 1 июнь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект документациясенә һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы бәяләмәсе составына, эчтәлегенә һәм аны рәсмиләштерү тәртибенә карата таләпләр раслау турында» 2018 елның 8 июнендәге 341/пр номерлы боерыгы (алга таба – 341/пр номерлы боерык); (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 21 август, бастырып чыгару номеры: 0001201808210039);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының»Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карары (алга таба – Министрлык турында нигезләмә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 28, 0642 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автономияле учреждениесен төзү турында» 2015 елның 20 февралендәге 102 номерлы карары (алга таба – 2015 елның 20 февралендәге 102 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, № 7, 0593 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

1.5 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).».»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты). Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелде.».

2 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты»;

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 4 пунктчасында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт экспертизасы уздыру вакытының максималь озынлыгы шартнамәдә билгеләнә, объектның катлаулылык дәрәҗәсеннән чыгып билгеләнә, ләкин 30 эш көненнән артып китәргә тиеш түгел. Төзүче оешма яки техник заказчы гаризасы нигезендә срок егерме эш көненнән артмаган чорга озынайтылырга мөмкин.»;

дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

2.9 пунктында «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезе:

а) төзелешкә яки үзгәртеп коруга төзелешкә рөхсәт алу таләп ителмәсә;

б) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау өчен әзерләнгән проект документациясе бүлекләренә карата, уртак файдаланудагы автомобиль юлларын капиталь ремонтлау өчен әзерләнгән проект документациясеннән тыш;

в) дәүләт экспертизасы дәүләт экспертизасын уздыру буенча бүтән оешма тарафыннан гамәлгә ашырылырга тиешле булса;

г) документлар түбәндәге таләпләрне бозып тапшырылган булса:

2016 елның 1 сентябреннән башлап төзелеше яки үзгәртеп корылышы тулысынча яки өлешчә федераль бюджет акчалары хисабыннан гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектларына карата әзерләнгән проект документациясе һәм (яки) инженерлык эзләнүләре, шулай ук проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә дәүләт экспертизасын уздыру өчен кирәкле документлар Россия Федерациясе төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениесенә электрон формада тапшырыла, проект документациясендә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрендә дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр булган очраклардан тыш;

2017 елның 1 гыйнварыннан башлап проект документациясе һәм (яки) инженерлык эзләнүләре, шулай ук проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә дәүләт экспертизасы уздыру өчен кирәкле документлар электрон формада тапшырыла, проект документациясендә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрендә дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр булган очраклардан тыш»;

2.10 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының җиденче абзацын көчен югалткан дип танырга;

2.16 пунктында:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Проект документациясе һәм (яки) инженерлык эзләнүләре, шулай ук проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләренә дәүләт экспертизасы уздыру өчен кирәкле документлар электрон формада тапшырыла, проект документациясенә һәм (яки) инженер эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын уздыру өчен кирәкле документларда дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр булган очраклардан тыш.

Алар ярдәмендә дәүләт экспертизасын электрон рәвештә уздыру мөмкин булган Интернет-сайтларның адреслары әлеге Административ регламентның 1.3.1 пунктында күрсәтелде.

Интернет-сайтлар түбәндәгеләрне тәэмин итә:

дәүләт экспертизасы уздыру турында гаризаны, дәүләт экспертизасы уздыру өчен кирәкле проект документациясен һәм бүтән документларны тутыруны һәм шәхси кабинет аша тапшыруны;

дәүләт экспертизасы барышы турында белешмәләрдән файдалану мөмкинлеген;

дәүләт экспертизасын уздырганда ачыкланган җитешсезлекләрне алуны, төзәтмәләр кертелгән документация бүлекләрен «ТР ДЭБКИ» ДАУ җибәрүне;

дәүләт эскпертизачын уздырганда электрон имзадан файдалануны.

Электрон формада тапшырылган документлар оешма җитәкчесе яки аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль законда каралган көчәйтелгән квалификацияле электрон имзадан файдаланып имзалана;

«Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ШрК 49 статьясының 5.3, 5.4, 7.1 өлешләре, Нигезләмәнең 39 пункты, 63-ФЗ номерлы федераль закон;

3 бүлектә:

3.8.1 пунктның икенче абзацында «887/пр номерлы» сүзләрен «341/пр номерлы» сүзләре белән алмаштырырга;

3.11 пунктка түбәндәге эчтәлекле кызыл юл өстәргә:

«Проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәсен бирү мондый бәяләмә турында белешмәләр капиталь төзелеш объектларының проект документацияләренә экспертиза бәяләмәләренең бердәм дәүләт реестрына кертелгәнчегә кадәр – рөхсәт ителми, проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын уздыру өчен кирәкле документларда дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр булган очраклардан тыш.»;

5 бүлектә:

5.2 пунктта:

3 пунктчада «каралмаган документларны тапшыруны» сүзләрен «тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматны тапшыруны яисә гамәлләрне башкаруны» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә яисә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яки документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.»;

5.5 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.»;

5.6 пунктны көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле $5.8^1$ һәм $5.8^2$ пунктлар өстәргә:

«$5.8^1$. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

$5.8^2$. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.»;

4 нче кушымтада «Объектның (проектлау биреме һәм проект документациясе нигезендә объектның аталышы) проект документациясенә дәүләт экспертизасын уздыруны сорыйм» җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектның (проектлау биреме һәм проект документациясе нигезендә объектның аталышы) проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасын уздыруны сорыйм.»;

7 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

## ЭКСПЕРТИЗА БӘЯЛӘМӘСЕНЕҢ НОМЕРЫ

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Х | Х | - | Х | - | Х | - | Х | - | Х | Х | Х | Х | Х | Х | - | Х | Х | Х | Х |

«РАСЛЫЙМ»

____________________________________

«___»_______________20__ ел.

## УҢАЙ (ТИСКӘРЕ) ЭКСПЕРТИЗА БӘЯЛӘМӘСЕ

Экспертиза объекты

______________________________________________________________________

Экспертиза объектының аталышы

## I. Экспертиза бәяләмәсе турында гомуми нигезләмәләр һәм белешмәләр

1.1. Экспертиза уздыручы оешма турында белешмәләр

____________________________________________________________________________

1.2. Мөрәҗәгать итүче, төзүче оешма, техник заказчы турында белешмәләр

____________________________________________________________________________

1.3. Экспертиза уздыру нигезләре

____________________________________________________________________________

1.4. Дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе турында белешмәләр

____________________________________________________________________________

1.5. Экспертиза уздыру өчен тапшырылган документлар составы турында белешмәләр

1) ________________________________________________________________;
2) ________________________________________________________________;
3) ________________________________________________________________.

## II. Проект документациясенә экспертиза уздыру өчен тапшырылган документлардагы белешмәләр

2.1. Үзенә карата проект документациясе әзерләнгән капиталь төзелеш объекты турында белешмәләр

2.1.1. Капиталь төзелеш объектының аталышы турында белешмәләр, аның почта (төзелү) адресы яки урнашкан урыны

____________________________________________________________________________

2.1.2. Капиталь төзелеш объектының функциональ билгеләнеше турында белешмәләр

____________________________________________________________________________

2.1.3. Капиталь төзелеш объектының техник-икътисадый күрсәткечләре турында белешмәләр

____________________________________________________________________________

2.2. Үзенә карата проект документациясе әзерләнгән катлаулы объект составына керә торган биналар (корылмалар) турында белешмәләр

1) ________________________________________________________________;
2) ________________________________________________________________;
3) ________________________________________________________________.

2.3. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлауны финанслау чыганагы (чыганаклары) һәм күләме турында белешмәләр

____________________________________________________________________________

2.4. Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау планлаштырылган территориянең табигый һәм техноген шартлары турында белешмәләр

---

2.5. Капиталь төзелеш объектын төзүнең, үзгәртеп коруның, капиталь ремонтлауның смета бәясе турында белешмәләр

---

2.6. Проект документациясен әзерләгән шәхси эшкуарлар һәм (яки) юридик затлар турында белешмәләр

---

2.7. Проект документациясен әзерләгәндә кабат кулланылышлы проект документациясеннән файдалану, шул исәптән кабат кулланылышлы проект документациясенең икътисадый нәтиҗәлелеге, турында белешмәләр

---

2.8. Проект документациясен эшләүгә төзүче оешма (техник заказчы) биреме турында белешмәләр

---

2.9. Территорияне планлаштыру документациясе турында, капиталь төзелеш объектын рөхсәтле төзү, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан чигенүгәрөхсәтләр булуы турында белешмәләр

---

2.10. Капиталь төзелеш объектларын инженер-техник тәэминат челтәрләренә тоташтыруның техник шартларын тәэмин итү турында белешмәләр

---

## III. Инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза уздыру өчен тапшырылган документлардагы белешмәләр

3.1. Инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре буенча хисап документациясен әзерләү датасы

---

3.2. Инженерлык эзләнүләре төрләре турында белешмәләр

---

3.3. Инженерлык эзләнүләрен уздыру районының (мәйданының, трассасының) урнашкан урыны турында белешмәләр

---

3.4. Инженерлык эзләнүләрен уздыруны тәэмин иткән төзүче оешма (техник заказчы) турында белешмәләр

---

3.5. Инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре буенча техник хисап әзерләгән шәхси эшкуарлар һәм (яки) юридик затлар турында белешмәләр

---

3.6. Инженерлык эзлцнълщрен башкаруга төзүче оешма (техник заказчы) биреме турында белешмәләр

___

3.7. Инженерлык эзләнүләре программасы турында белешмәләр

___

## IV. Каралган документларга (материалларга) тасвирлама

4.1. Инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләрен тасвирлау

4.1.1. Инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре турында хисап материалларының составы (экспертиза уздыру барышында кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып)

| Том №ы | Билгесе | Атальшы | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| | | | |

4.1.2. Инженерлык эзләнүләрен башкару методлары турында белешмәләр

___

4.1.3. Экспертиза уздыру процессында инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә мөрәҗәгать итүче тарафыннан кертелгән оператив үзгәрешләр турында белешмәләр

___

4.2. Проект документациясенең техник өлешенә тасвирлама

4.2.1. Проект документациясенең составы (экспертиза уздыру барышында кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып)

| Том №ы | Билгесе | Атальшы | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| | | | |

4.2.2. Проект документациясендә кабул ителгән төп чишелешләргә (чараларга) тасвирлама
1) ___;
2) ___;
3) ___.

4.2.3. Экспертиза уздыру процессында проект документациясенең карал торган бүлекләренә мөрәҗәгать итүче тарафыннан кертелгән оператив үзгәрешләр турында белешмәләр

___

## V. Карау нәтиҗәләре буенча йомгаклар

5.1. Инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренең техник регламентларның таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында нәтиҗәләр

___

5.2. Проект документациясенең техник өлешенә карата нәтиҗәләр

5.2.1. Проект документациясенә туры килү-килмәвенә карата бәяләү уздырылган инженерлык

эзләнүләре нәтиҗәләренә күрсәтү

_______________________________________________

5.2.2. Проект документациясенең техник өлешенең инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә һәм техник регламентларның таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турында нәтиҗәләр

_______________________________________________

## VI. Гомуми нәтиҗәләр

_______________________________________________

## VII. Экспертиза бәяләмәсен имзалаган, экспертиза бәяләмәләрен әзерләү хокукына аттестатланган затлар турында белешмәләр

1) ____________________________________________;
2) ____________________________________________;
3) ____________________________________________.».